# КАРАР

**« 16 » ноябрь 2024 ел № 11**

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «Апаз авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, 2024 елның 16 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыены нәтиҗәсе белән халык җыены йомгаклау беркетмәсе төзелде:

«2025 елда Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 3000 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамыннан Пөшәңгәр авылының Нагорная урамына кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын ташлы балчык, вак таш җәеп тигезләү, бишенче этабы; Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю);
- янгынга каршы резервуарлар (янгынга каршы су җыю урыннары), янгын пирслары ясау, ремонтлау (янгынга каршы ёмкостька электр насосы сатып алу һәм урнаштыру);
- коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (инвентарь саклый торган зират өен тышлау)»?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Җыенда катнашучы сайлау хокукына ия затлар исемлегенә 36 граждан, тавыш бирүдә катнашкан 26 кеше кертелде.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашучы 26 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче торак пунктында халык җыены узды, җыен нәтиҗәләре дөрес дип танырга.

2. «2025 елда Апаз авыл җирлеге Кзыл-Игенче авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, түләү күләме 3000 сум тәшкил иткән үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм җыйналган акчаның түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә тотылуына сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (вак таш сатып алу; Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамыннан Пөшәңгәр авылының Нагорная урамына кадәрге җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлын ташлы балчык, вак таш җәеп тигезләү, бишенче этабы; Кзыл-Игенче авылының Дальняя урамында автомобиль юлын тигезләү өчен вак таш җәю);
- янгынга каршы резервуарлар (янгынга каршы су җыю урыннары), янгын пирслары ясау, ремонтлау (янгынга каршы ёмкостька электр насосы сатып алу һәм урнаштыру);
- коймалар кору, күмү урыннарын төзекләндерү (инвентарь саклый торган зират өен тышлау)»?

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ””

мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип танырга.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, ТР, Арча районы, Кзыл-Игенче авылы, Дальняя урамы, 16 йорт адресы буенча мәгълүмат стендларында, Арча муниципаль районының (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Апаз авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Апаз авыл җирлеге башлыгы Р.Ф.Котдусов